«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры

_______________ Э.Н. Фәттахов

"___"___________ 2016 нчы ел

# ТАТАР ТЕЛЕ

## Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының рус төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына 2017 нче елда ТАТАР ТЕЛЕННӘН бердәм республика тесты уздыру өчен контроль бәяләү материалларының үзенчәлекләре (спецификация)

**Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәпләренең**
**рус төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына 2017 нче елда**
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН бердәм республика тесты уздыру**
**өчен материалларның үзенчәлекләре**
**(спецификация)**

**1. Бердәм республика тестын уздыруның максаты** – рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәпләренең IX сыйныфын тәмамлаучы укучыларның татар теленнән әзерлек дәрәҗәләрен бәяләү.

**2. Бердәм республика тестының эчтәлеген билгеләүче документ**
Хәйдәрова Р.З., Фәтхуллова К.С., Әхмәтҗанова Г. М. Төп гомуми белем бирү мәктәбе өчен татар теленнән үрнәк программа (5-9 нчы сыйныфлар). - Казан, 2013.

**3. Эчтәлекне сайлау һәм үрнәк материалларны төзү алымнары**
Төп гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен укытуның максаты - укучыларда коммуникатив компетенция (аралашу осталыгы) формалаштыру.

Төп гомуми белем бирү мәктәбен тәмамлаучыларның коммуникатив эшчәнлеген һәм тел күнекмәләре дәрәҗәсен билгеләү өчен, бердәм республика тестында төрле типтагы биремнәр файдаланыла.

Укучыларның тәкъдим ителгән биремнәрне башкарып чыгуы аларның татар телен үзләштерү дәрәҗәсен ачыкларга ярдәм итә.

**Бердәм республика тестының (БРТ) төзелеше һәм эчтәлеге**

БРТ 4 бүлектән тора. Бу бүлекләрдә 3 төрле төзелешкә ия биремнәр урын ала.

Укучыга татар теленнән БРТ вакытында тәңгәллек урнаштыруга караган – 3 бирем, тәкъдим ителгән 2 җавапның берсен сайлап алу мөмкинлеге булган – 8, тәкъдим ителгән 3 җавапның берсен сайлап алу мөмкинлеге булган – 6 бирем, кыска җавап бирүне таләп иткән – 15, сөйләм ситуацияләренә караган 5 бирем һәм киңәйтелгән җавап (язма текст) язуны таләп иткән ачык типтагы 1 бирем тәкъдим ителә.

*Төзелеше ягыннан* татар теленнән тест эше өч өлештән тора.

1 нче өлеш (1 – 17 нче биремнәр) җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәрдән тора. Бу өлештә тәкъдим ителгән биремнәр укучыларның тыңланган һәм укылган текстларның төп эчтәлеген аңлау һәм алардан кирәкле мәгълүматны табу күнекмәләрен тикшерүгә юнәлдерелгән.

2 нче өлеш (18 –32 нче биремнәр) кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәрдән тора. Бу өлештә тәкъдим ителгән биремнәр укучыларның лексик-грамматик күнекмәләрен тикшерүгә юнәлдерелгән.

3 нче өлеш (33 – 38 нче биремнәр) сөйләм ситуацияләренә караган репликалар язуны күздә тоткан биремнәрдән (33-37 нче биремнәр) һәм укучыларның билгеле бер темага караган язма сөйләмен тикшерүгә юнәлдерелгән ачык типтагы биремнән (38 нче бирем – шәхси хат язу) тора.

Тест эшендә биремнәрнең чагылышы 1 нче таблицада бирелә.

*1 нче таблица*

*Биремнәрнең тест эшендә чагылышы*

<table>
<tr><th></th><th>Биремнәрнең саны</th><th>Башлангыч (максималь) иң югары балл</th><th>Биремнәрнең төрләре</th></tr>
<tr><td>Тыңлап аңлау биремнәре</td><td rowspan="2">17</td><td rowspan="2">30</td><td rowspan="2">Җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр</td></tr>
<tr><td>Аңлап уку биремнәре</td></tr>
<tr><td>Лексик һәм грамматик белемнәрне тикшерү биремнәре</td><td>15</td><td>15</td><td>Кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Язу күнекмәләрен тикшерү биремнәре</td><td>5</td><td>10</td><td>Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнәр</td></tr>
<tr><td>1</td><td>10</td><td></td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>38</td><td>65</td><td></td></tr>
</table>

## **5. Тест биремнәрен эчтәлекләре һәм эш төрләренә нигезләнеп бүлү**

Тестта төп гомуми белем бирү мәктәбендәге рус телле укучыларның татар телендә коммуникатив компетенциягә ия булулары тикшерелә. Ягъни:

- тыңланган текстның төп эчтәлеген һәм сорала торган мәгълүматны аңлый белү (1 нче бүлек);
- укылган текстның төп эчтәлеген һәм сорала торган мәгълүматны аңлый белү (2 нче бүлек );
- тел берәмлекләрен коммуникатив яктан мөһим булган контекстта куллану күнекмәләренә ия булу (3 нче бүлек);
- тәкъдим ителгән сөйләм ситуациясе буенча реплика яза белү (4 нче бүлек);

- стимул-хатка җавап итеп шәхси хат яза белү (4 нче бүлек).

Әлеге бүленеш 2 нче таблицада күрсәтелә.

*2 нче таблица*

**Сөйләм осталыгы һәм тел берәмлекләрен куллану күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр бүленеше**

| **Сөйләм осталыгы һәм тел күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр** | **Биремнәрнең саны** | **Иң югары башлангыч балл** |
|---|---|---|
| Тыңланган текстның төп эчтәлеген аңлау | 2 | 9 |
| Тыңланган тексттагы кирәкле мәгълүматны табу | 6 | 6 |
| Укылган текстның төп эчтәлеген аңлау | 8 | 8 |
| Укылган тексттагы кирәкле мәгълүматны табу | 1 | 7 |
| Грамматик күнекмәләр | 8 | 8 |
| Лексик-грамматик күнекмәләр | 7 | 7 |
| Сөйләм бурычын аңлау күнекмәләре<br>Сөйләм ситуациясенә караган репликаларны язу | 5 | 10 |
| Билгеле бер тема, проблема буенча яза белү күнекмәләре<br>Хат язу | 1 | 10 |
| *Барлыгы* | 38 | 65 |

## 6. Биремнәрне катлаулылыгы дәрәҗәсеннән чыгып бүлү

Бердәм республика тестының катлаулылык дәрәҗәсе тел материалының һәм тикшерелә торган күнекмәләрнең катлаулылыгы дәрәҗәсеннән, шулай ук биремнең төреннән чыгып билгеләнә.

Бердәм республика тестында 2 төрле катлаулылыктагы биремнәр тәкъдим ителә.

*Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе буенча бүленеше*

*3 нче таблица*

| **Биремнәрнең катлаулылык дәрәҗәсе** | **Биремнәрнең саны** | **Иң югары башлангыч балл** | **Иң югары башлангыч баллдан чыгып, биремнәрнең әлеге өлеше өчен куелган иң югары** |
|---|---|---|---|

| | | | **башлангыч баллның проценты** |
|---|---|---|---|
| Беренче дәрәҗә | 23 | 26 | 40% |
| Икенче дәрәҗә | 15 | 39 | 60 % |
| Барлыгы | 38 | 65 | 100 % |

**7. 1 нче (тыңлап аңлау биремнәре) һәм 2 нче (уку өчен тәкъдим ителгән биремнәр) бүлекләрдә кулланыла торган текстларның жанрлары һәм стильләре**

1 нче бүлектә (**тыңлап аңлау биремнәре**) әңгәмәдәшләрнең көндәлек аралашу вакытында куллана торган гыйбарәләре, прагматик (белдерү) һәм мәгълүмати аудиотекстлар файдаланыла.

Тыңлап аңлау текстларының озынлыгы 2,5 – 3 минутлык була. Тыңлап аңлау өчен тәкъдим ителгән текстларны тел вәкиле укый.

2 нче бүлектә (**уку өчен тәкъдим ителгән биремнәр**) прагматик, фәнни-популяр, публицистик һәм әдәби стильгә караган текстлар файдаланыла. Уку өчен **тәкъдим ителгән** текстларның күләме, тикшерелә торган күнекмәләр һәм белемнәрнең тирәнә, биремнең характерына карап, 150-200 сүз тәшкил итә*.

**8. Текстларның якынча тематикасы.**

Бердәм республика тестында түбәндәге темаларга караган текстлар файдаланыла:

1. Үзем һәм гаиләм турында. Туганлык мөнәсәбәтләре.
2. Көндәлек тормышта аралашу.
3. Көндәлек режим. Буш вакытым.
4. Бәйрәмнәр.Татар һәм рус халыкларының милли бәйрәмнәре һәм йолалары. Котлаулар.
5. Минем яраткан шөгыльләрем һәм уеннарым. Минем дөньям һәм Интернет. Спорт уеннары.
6. Мин һәм минем дусларым. Дуслык
7. Кешенең тышкы кыяфәте һәм холкы.
8. Мәктәбем һәм сыйныфым. Дәресләр. Түгәрәкләр, спорт секцияләре. Сыйныфташлар белән үзара мөнәсәбәтләр.
9. Һөнәрләр.
10. Өлкәннәргә хөрмәт.
11. Әйләнә-тирә дөнья. Йортым, фатирым. Туган шәһәрем/авылым.
12. Туган як табигате. Табигать һәм кеше. Ел фасыллары. Экология.
13. Татарстан Республикасы. Гомуми мәгълүмат: исеме, башкаласы, шәһәрләре халкы, елгалары, истәлекле урыннары.

---

* 24 нче код буенча төзелгән (җиңеләйтелгән биремнәрдән торган) вариантта 100-160 сүз.

14. Мәдәният, сәнгать.
15. Илләр һәм шәһәрләр.
16. Сәяхәт итү. Җәйге ял. Кышкы ял.
17. Татар халкының күренекле шәхесләре.

**9. Эшне башкару вакыты**

Тест үтү өчен, 2,5 сәгать (150 минут) вакыт бирелә.

**10. Өстәмә материаллар һәм җиһазлар**

Тест вакытында тавыш яңгырату аппаратурасы, татар теленең орфографик сүзлеге, 1 нче бүлек биремнәрен (тыңлап аңлау) үтәү өчен, текстлар яздырылган компакт-диск һәм стена сәгате файдаланыла. Орфографик сүзлекләрдән файдаланырга мөмкин.

**11. Аерым биремнәрне һәм эшне тулаем бәяләү системасы**

Җавабын сайлап алу мөмкинлеге булган һәм кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәргә дөрес җавап биргән өчен, укучы 1 балл ала. Җавап дөрес булмаса яки бөтенләй бирелмәсә, 0 балл куела. 1 нче, 2 нче һәм 17 нче биремнәрдә һәр дөрес тәңгәллек аерым бәяләнә. 1 нче биремне үтәгән өчен, укучы 0 дән 4 баллга кадәр, 2 нче бирем өчен - 0 дән 5 баллга кадәр, 17 нче бирем өчен 0 дән 7 баллга кадәр җыя ала.

4 нче бүлек биремнәрен тикшерү махсус әзерләнгән критерийлар нигезендә башкарыла һәм укучыга бу өлештә барлыгы 20 балл куела. 33-37 нче биремнәрдә, сөйләм бурычын аңлап, аңа туры килгән 5 реплика язарга кирәк. Һәр реплика максималь 2 балл белән бәяләнә. Сөйләм репликалары барысы да дөрес язылса, укучы 10 балл ала. 38 нче биремне тикшергәндә, язма эшнең күләме, андагы сүзләрнең саны да исәпкә алына. Укучыдан 80 (җиңеләйтелгән биремнәрне башкаручылардан 40) сүздән торган иҗади эш язу сорала. Язма эшнең эчтәлеге һәм грамоталылыгы өчен укучы 10 балл ала. Эшнең күләме 40 (20) сүздән артмаса, текстның лексик-грамматик төзелеше (К3), орфография һәм пунктуация (К4) критерийлары өчен эшкә максималь балл куелмый.

Укучыга, гомумән, БРТ өчен максималь 65 балл куела.

БРТ үтү алдыннан укучыларның әлеге эше өчен куела торган минималь баллның күләме билгеләнә. Ул төп гомуми белем бирү мәктәбенең 9 сыйныфында укучы рус телле укучыларның татар теленнән белем һәм күнекмәләренең минималь күләмен ачыклый.

Минималь баллдан югарырак баллар җыйган укучы түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиеш:

- тыңланган текстның төп эчтәлеген аңлау;
- тыңланган тексттан кирәкле мәгълүматны табу;
- укылган текстның төп эчтәлеген аңлау;
- укылган тексттан кирәкле мәгълүматны табу;

- лексик-грамматик һәм орфографик күнекмәләргә ия булу;
- билгеле бер тема, проблема буенча язма сөйләм һәм сөйләм ситуацияләренә караган репликаларны язу күнекмәләре.

**12. Бердәм республика тестын үткәрү һәм эшләрне тикшерүгә куелган таләпләр**

Бердәм республика тесты махсус пунктларда уздырыла. Әлеге пунктлар гомуми белем бирү оешмалары базасында оештырыла.

Татар теленнән тест үткәрелә торган бүлмәләргә татар теле һәм әдәбияты белгечләре кертелми.

Тестны үткәрүдә андагы укучылар белән эшләмәгән педагог кына катнаша ала.

Тестның барлык бүлекләрендәге биремнәрне үтәгәндә, укучыларга орфографик сүзлектән файдаланырга рөхсәт ителә.

1 нче номерлы җаваплар бланкы (1 нче – 32 нче биремнәрнең җаваплары язылган бланк) сканерланганнан соң, автоматик эшкәртүгә тапшырыла.

Киңәйтелгән җавап бирүне таләп иткән биремнең дөреслеген махсус әзерлек узган татар теле белгечләре тикшерә.

**13. 2017 нче елда татар теленнән бердәм республика тесты уздыру өчен үрнәк материалларның гомумиләштерелгән планы.**

2017 нче елда татар теленнән бердәм республика тесты уздыру өчен биремнәрнең эчтәлеге Кушымтада китерелгән гомумиләштерелгән планда чагыла.

Кушымта

**Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәпләренең рус төркемнәрендәге IX сыйныф укучыларына татар теленнән 2017 нче елда бердәм республика тесты уздыру өчен үрнәк материалларның гомумиләштерелгән планы**

***Шартлы кыскартулар: ВО -*** *җавапның берсен сайлап алу мөмкинлеге булган биремнәр; КО - кыска җавап бирүне таләп иткән биремнәр; РО - киңәйтелгән җавап (язма текст) бирүне таләп иткән биремнәр.*

| Биремнәрнең номеры | Тикшерелә торган эшчәнлек төре | Тикшере-лә торган элементның коды | Катлаулык дәрәҗәсе | Биремнең тибы | Тәкъдим ителә торган вакыт |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Тыңланган текстның төп эчтәлеген аңлау | 1.1 | 1 | ВО | 15 |
| 2. | | | 2 | ВО | |
| 3. | Тыңланган тексттан кирәкле мәгълүматны аңлау һәм табу | 1.2 | 1 | ВО | 15 |
| 4. | | | 1 | ВО | |
| 5. | | | 1 | ВО | |
| 6. | | | 1 | ВО | |
| 7. | | | 1 | ВО | |
| 8. | | | 1 | ВО | |
| 9. | Укылган тексттан кирәкле мәгълүматны аңлау һәм табу | 2.1, 2.3 | 1 | ВО | 30 мин |
| 10. | | | 1 | ВО | |
| 11. | | | 1 | ВО | |
| 12. | | | 1 | ВО | |
| 13. | | | 1 | Во | |
| 14. | | | 1 | ВО | |
| 15. | | | 1 | ВО | |
| 16. | | | 1 | ВО | |
| 17. | Укылган текстның төп эчтәлеген аңлау | 2.1, 2.2, 2.3, | 2 | ВО | |
| 18. | Бирелгән сүзне кирәкле | 4.1 | 1 | КО | 30 мин |
| 19. | | | 1 | КО | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 20. | грамматик формада куллану күнекмәләре | | 1 | КО | |
| 21. | | | 1 | КО | |
| 22. | | | 1 | КО | |
| 23. | | | 1 | КО | |
| 24. | | | 1 | КО | |
| 25. | | | 1 | КО | |
| 26. | Тамырдаш сүзләр ясау һәм аларны кирәкле грамматик формада куллануны таләп иткән лексик-грамматик күнекмәләр | 4.2 | 2 | КО | |
| 27. | | | 2 | КО | |
| 28. | | | 2 | КО | |
| 29. | | | 2 | КО | |
| 30. | | | 2 | КО | |
| 31. | | | 2 | КО | |
| 32. | | | 2 | КО | |
| 33. | Төрле сөйләм ситуацияләренә караган репликаларны язу | 3.4, 3.5 | 2 | РО | 20 мин |
| 34. | | | 2 | РО | |
| 35. | | | 2 | РО | |
| 36. | | | 2 | РО | |
| 37. | | | 2 | РО | |
| 38. | Сорауларга җавап биреп, шәхси хат язу | 3.1, 3.2, 3.3, 3.5 | 2 | РО | 40 мин |

Барлыгы 38 бирем. Шуларның:
биремнәрнең төре буенча: ВО – 17, КО – 15, РО – 6.
катлаулылык дәрәҗәсе буенча:
1 нче дәрәҗә – 23 бирем;
2 нче дәрәҗә – 15 бирем.
Эшне башкару вакыты – 150 мин.